**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Ш. Марджани, дом 6

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Ш. Мәрҗани урамы, 6 нчы йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«10» 04 2026 г.** **№ 35**

**Әтнә муниципаль районының 2026 елның 01 апреленә бюджет үтәлеше турында**

Әтнә муниципаль районының финанс-бюджет палатасы Рәисе Ф.И. Гыймадиевның «Әтнә муниципаль районының 01.04.2026 елга бюджет үтәлеше турында»гы докладын тыңлагач һәм фикер алышкач, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджетын үтәү буенча 01.04.2026 елга канәгатьләнерлек эшне билгеләп үтәргә.

2. 2026 елның 1 апреленә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджеты үтәлеше турындагы хисапны керемнәр буенча 281856,5 мең сум күләмендә һәм чыгымнар буенча 300804,2 мең сум күләмендә, 18947,7 мең сум күләмендә керемнәрдән чыгымнар артып (муниципаль район бюджеты дефицит), әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә, расларга.

3. Әтнә муниципаль районы бюджеты үтәлеше буенча 2026 елның 1 апреленә түбәндәге күрсәткечләрне расларга:

- Әтнә муниципаль районы бюджетының 01.04.2026 елга үтәлеше турында хисап;
- Әтнә муниципаль районы бюджетының керемнәре бюджет керемнәренең классификация кодлары буенча, әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә;
- Әтнә муниципаль районы бюджеты чыгымнары бюджет чыгымнарын классификацияләү бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча, әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә;
- Әтнә муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча Әтнә муниципаль районы бюджеты чыгымнары, әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә;
- Әтнә муниципаль районының максатчан статьялары (дәүләт һәм муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре, буенча бюджет чыгымнары әлеге, карарның 5 нче кушымтасы нигезендә;
- Әтнә муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча, әлеге карарның 6 нчы кушымтасы нигезендә.

4. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының www.atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы www.pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Әтнә муниципаль районы башлыгы -
Әтнә район Советы рәисе Р.Ш.Хисамиев